КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 май г.Казань № 432

Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 27 май, 432 нче
карары белән расланды

## Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенең (алга таба – Фонд) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче чараларын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели.

Субсидияләр Фондка сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә күчемсез мөлкәт объектлары арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (алга таба – субсидия) бирелә.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр:

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

заем – сәнәгать (индустриаль) парклар, сәнәгать мәйданчыклары инфраструктурасын үстерү өчен Фонд тарафыннан сәнәгать (индустриаль) паркының, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясенә елына 0,1 процент белән бирелә торган акча;

резидент – идарә итүче компания йә агент белән сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары арендасы турында төзегән гамәлдәге шартнамәсе булган хуҗалык итүче субъект (юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр);

агент – резидентлар белән идарә итүче компаниягә караган күчемсез мөлкәт объектлары арендасы шартнамәсен төзегән һәм идарә итүче компания белән төзелгән шартнамә нигезендә аның кушуы буенча резидент белән күчемсез мөлкәт объектлары

арендасы шартнамәсе буенча юридик һәм башка гамәлләр башкара торган хуҗалык итүче субъект (юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр);

сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары инфраструктурасын үстерү (алга таба – инфраструктураны үстерү) – Татарстан Республикасы сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының коммуналь һәм юл инфраструктурасы объектларын карап тоту, төзү, модернизацияләү һәм (яки) реконструкцияләү;

коммуналь инфраструктура – сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары территориясендә һәм алар янындагы территориядә урнашкан һәм резидентлар эшчәнлеген тәэмин итә торган, электр, газ, җылылык, су белән тәэмин итү, су чыгару, электр энергетикасы өлкәсендә товарлар кайтартуны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар комплексы;

юл инфраструктурасы – сәнәгать (индустриаль) парклары, сәнәгать мәйданчыклары территориясендә һәм алар янындагы территориядә урнашкан һәм резидентлар эшчәнлеген тәэмин итә торган автомобиль юллары;

сәнәгать (индустриаль) паркының, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе (алга таба – идарә итүче компания) – кимендә 70 резидент белән, шул исәптән агентны җәлеп итеп төзелгән гамәлдәге күчемсез мөлкәт объектлары арендасы шартнамәләре булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә мөлкәти ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 ел, 27 август, 616 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында 2018 елдан иртәрәк алынмаган таныклыгы булган хуҗалык итүче субъект (юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр);

күчемсез мөлкәт объектлары арендасыннан алып бетерелмәгән керем – идарә итүче компания тарафыннан гамәлдәге күчемсез мөлкәт объектлары арендасы шартнамәләре буенча резидентларга түләү вакытын кичектереп яки ташламалар биреп алынмаган аренда түләүләре суммасы.

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына субсидия бирү өчен вәкаләтле органга бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Фонд субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзергә планлаштырыла торган айның беренче көненә туры килергә тиешле таләпләр:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау.

5. Субсидия алу өчен Фонд вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча заявка;

гамәлгә кую документларының күчермәләрен;

агымдагы финанс елына һәм план чорына Фонд Советы тарафыннан хупланган Фондны үстерү концепциясен;

Фондның бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны;

бу Тәртипнең 11 нче пунктында билгеләнгән формула нигезендә, бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидияләр күләмен исәпләү өчен башлангыч мәгълүматларны теркәп, субсидия күләме исәп-хисабын;

бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы резидентларыннан мөрәҗәгатьләр реестрын.

Фонд үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Фондны юридик зат буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсен);

Фондны салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Фонд тарафыннан бу пунктның тугызынчы, унынчы һәм унберенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, вәкаләтле орган әлеге документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

6. Заявка вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны теркәү журналында кергән көнне теркәлә, ул номерланган, шнурланган һәм мөһер белән беркетелгән булырга тиеш. Вәкаләтле орган заявканы теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аның бу Тәртип таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Фонд тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Фондның бу Тәртипнең 4 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Фонд тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

8. Вәкаләтле орган Фондка субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.

9. Субсидия бирү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турында карар кабул ителгән

көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә вәкаләтле орган белән Фонд арасында төзелгән Килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлеше, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

субсидияне күчерү вакытлары һәм тәртибе;

Фонд тарафыннан өстәмә хисаплылык тапшыру формасы, тәртибе һәм вакытлары (кирәк булганда);

аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, субсидияне кире кайтару очраклары;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен (Фондның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган акчалата йөкләмәләренә түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелә торган субсидиядән тыш) кире кайтару очраклары, әгәр дә вәкаләтле орган тарафыннан агымдагы финанс елында бу акчаны субсидия бирү максатларына файдалану турында карар кабул ителмәгән булса;

штраф санкцияләрен куллану очраклары һәм тәртибе;

вәкаләтле орган тарафыннан субсидиянең калган өлешләрен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алу (югары технологияле чит ил җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (аларны кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш);

Фонд тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган Килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмә;

Фондның һәм Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән заем шартнамәләре буенча заемнар алучылар булган идарә итүче компанияләрнең вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан аларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен гамәлгә ашыруга ризалыгы;

идарә итүче компанияләргә заемнар бирү нәтиҗәләре, идарә итүче компанияләр тарафыннан заемнар бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык бирү тәртибе, вакытлары һәм формалары.

Кирәк булганда, вәкаләтле орган Фонд белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә Килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

10. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр була:

идарә итүче компанияләргә бирелгән заемнар саны;

заемнар бирелгән идарә итүче компанияләр саны.

11. Бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Фондка бирелә торган субсидия күләмен (С) исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$C = \sum_{i=1}^{n} D,$$

монда:

n – заемнар бирү планлаштырыла торган идарә итүче компанияләр саны;

D – субсидия биргән ай алдыннан килгән бер ай өчен идарә итүче компания тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары арендасыннан алып бетерелмәгән керем күләме.

Сәнәгать (индустриаль) паркының, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе резидентлары тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары арендасыннан алып бетерелмәгән кеременең беренче исәп-хисабы 2020 елның апреле өчен гамәлгә ашырыла. Алга таба исәп-хисап бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ихтыяҗ булган һәм өстәмә ассигнованиеләр бүлеп бирелгән очракта, субсидия биргән ай алдыннан килгән ай өчен гамәлгә ашырыла.

12. Вәкаләтле орган субсидияне Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Фондның Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

13. Фонд, субсидия биргән елдан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга түбәндәге хисапларны тапшыра:

төзелгән шартнамәләрне теркәп, бу Тәртипнең 3 нче кушымтасында бирелгән форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап;

бу Тәртипнең 4 нче кушымтасында бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап.

14. Субсидия Фонд тарафыннан түбәндәге очракларда вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланганда;

Фонд тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылганда;

Фонд тарафыннан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплар, өстәмә хисаплылык тапшырылмаганда (әгәр ул Килешү белән каралган булса);

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешелмәгәндә;

Фонд тарафыннан субсидия акчасы максатчан файдаланылмаганда.

Әгәр дә Фонд Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешмәгән булса, вәкаләтле орган Фондка карата штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә, бу турыда Фондка әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә мәҗбүри хәбәр итә.

Әлеге очракта штраф санкцияләре күләме (A) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$A = \left( \sum_{i=1}^{2} \left( 1 - \frac{d_i}{D_i} \right) \times X \right) \times V,$$

монда:

i – бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$\mathbf{d_i}$ – субсидия бирү i-нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе;

$D_i$ – Килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү i-нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе;

X – хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкы төп ставкасының өч йөздән бер өлешенә тигез булган төзәтү коэффициенты;

V – Фонд тарафыннан алынган субсидия акчасы күләме.

Субсидия бирү нәтиҗәләренең берсен исәпләп чыгарганда факттагы мәгънә план мәгънәсеннән артып китсә, бу нәтиҗә буенча формуланың мәгънәсе нульгә тигез итеп алына.

15. Хисап финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше вәкаләтле орган тарафыннан әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракларда файдаланылырга мөмкин.

Вәкаләтле органның хисап финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗ булу турындагы карары булмаган очракта, әлеге акча хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

16. Фонд тарафыннан бу Тәртипнең 14, 15 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару вакытлары бозылганда вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарыла торган тиешле субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

17. Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары Фондка субсидия бирүнең бу Тәртиптә һәм Килешүдә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

2020 елның ___________ ына (енә) субсидияләр күләмен исәпләү өчен башлангыч мәгълүматлар
(ай)

| Т/с | Сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе исеме | Алып бетерелмәгән керем суммасы | Керем алып бетерелмәгән чор |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| … | | | |
| Барлыгы | | | |

Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгы резидентларыннан мөрәҗәгатьләр реестры

| Сәнәгать (индустриаль) паркы, сәнәгать мәйданчыгының идарә итүче компаниясе исеме | Т/с | Резидент исеме | ИНН | Икътисадый эшчәнлек төрләренең төп гомумроссия классификаторы | Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторын таркатып язу | Аренда шартнамәләре буенча кичектереп тору, ташламалар бирү вакыты | Аренда мәйданының күләме, кв.метр | 1 кв.метр өчен бәясе, сум | аренда шартнамәләре буенча бер айга соратып алына торган кичектереп тору, ташлама % | 2020 елның _______ өчен күчемсез мөлкәт объектлары арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләме, сум | Раслый торган документ (резидент хаты-мөрәҗәгате, башка документлар) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

2020 елның «___» _______ына (енә) финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап

«Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе.
Тапшыру вакыты: еллык.
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унарлы билгегә кадәр төгәл итеп).

| Күрсәткеч исеме | Юл коды | Субсидияләрне тоту юнәлеше коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|---|
| | | | хисап чоры | ел башыннан арта бара торган йомгак белән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Субсидиянең калган өлеше – барлыгы, | 100 | - | | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗ булуы расланган | 110 | - | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | 120 | | | |
| Акча керде – барлыгы, | 200 | - | | |
| шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан | 210 | - | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| үткән елларның дебиторлык бурычы | 220 | - | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр – барлыгы, | 300 | | | |
| шул исәптән:<br>сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә заемнар бирү – барлыгы, | 310 | | | |
| шулардан: | | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылды – барлыгы, | 400 | - | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча тотылмаган | 410 | - | | |
| штраф санкцияләре куллану нәтиҗәсендә | 420 | - | | |
| Хисап чоры ахырына субсидиянең калган өлеше – барлыгы, | 500 | - | | |
| шул исәптән:<br>шул ук максатларга юнәлдерүдә таләп ителә | 510 | - | | |
| кире кайтарылырга тиеш | 520 | - | | |

Җитәкче ___________________ _____________ _________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы _________________ __________________________ ______________
(вазыйфасы) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

20__ , «__» ________

Сәнәгать (индустриаль) паркларының, сәнәгать мәйданчыкларының идарә итүче компанияләренә аларның инфраструктурасын үстерүгә мөлкәт арендасыннан алып бетерелмәгән керемнәр күләмендә заемнар бирү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен 2020 елда «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Форма

2020 елның «___» ____________ы(е) хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

«Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе
Тапшыру вакыты: еллык.

| Т/с | Субсидия бирү нәтиҗә-сенең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе | Субсидияләр бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү про-центы | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Җитәкче __________________ _____________ _________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы _________________ __________________________ ______________
(вазыйфасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)) (телефоны)

20__ , «__» ________

____________________________